| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2021 Казан ш. № 636-28/э-2021

«Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 № 3-12/э карары белән билгеләнгән озак сроклы индивидуаль тарифларга 2022 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларының кирәкле тулай табышына 2022 ел өчен үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2023 елларга «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә индивидуаль тарифлар билгеләү турында» 14.12.2018 № 3-12/э карары кушымтасына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2019 № 3-24/э,

16.12.2020 № 442-14/э-2020 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В.Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2018 № 3-12/э карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2021 № 636-28/э-2021 карары
редакциясендә) 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2019 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар

| Т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2019 | 620124,79 | 175,62 | 1,90994 | 620 124,79 | 187,74 | 1,92206 |
| | | 2020 | 488 133,29 | 271,68 | 1,42979 | 488 133,29 | 271,68 | 1,42979 |
| | | 2021 | 497 504,11 | 300,18 | 1,37764 | 497 504,11 | 300,18 | 1,37764 |
| | | 2022 | 554 350,51 | 317,58 | 1,51903 | 554 350,51 | 317,58 | 1,51903 |
| | | 2023 | 701 929,70 | 212,54 | 2,17565 | 701 929,70 | 212,54 | 2,17565 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2018 № 3-12/э карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2021 № 636-28/э-2021 карары
редакциясендә) 3 нче кушымта

«Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2019-2023 елларга кирәкле тулай керемнәре (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| Т/с | Татарстан Республикасындагы челтәр оешмасының исеме | Ел | Югалтуларны исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2019 | 81 856,47 |
| | | 2020 | 84 935,19 |
| | | 2021 | 86 923,92 |
| | | 2022 | 97 105,64 |
| | | 2023 | 92 654,72 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге